Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Урман Көләй авыл Советы

КАРАРЫ

25 февраль 2022 ел № 36

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Урман Көләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының « Урман Көләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Көләй авыл Советының 2015 елның 27 февралендәге 184 номерлы карары белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру (кабул итү) турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Урман Көләй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан килешүләр төзү тәртибе нигезендә

Урман Көләй авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1.«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Көләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшырырга:

-җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт белән эш итү;

- җирлекнең муниципаль мөлкәте реестрын алып бару.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына карауга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының « Урман Көләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларны билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. « Урман Көләй авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен Әлмәт муниципаль районына тапшыру турында» 2020 елның 12 маендагы 169 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Урман Көләй авыл Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Урман Кәләй авылы, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты; Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Урман Кәләй авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Урман Кәләй авыл җирлеге
башлыгы Л.Н. Фәләхиев